| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Сарман муниципаль районының Иске Имэн авыл җирлеге |
|---|---|---|

КАРАР КАРАР

19 сентябрь 2017 ел №64

**Референдум уздыруны инициацияләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Иске Имән авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2018 елда үзара салым кертүгә Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт итүче гражданнардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру шул исәптән, уздыруны оештыру;

- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыру өчен бүләкләр алу.

2) Җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп), шул исәптән:
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында урамнарны яктырту лампаларын алыштыру;
- Иске Имән авылында һәйкәл һәм койма ремонтлау өчен буяу сатып алу;
- Иске Имән авылында балалар урам комплексы сатып алу;
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында зур агачларны кисү;
-Беларус-МТЗ 320.4-с махсус техникасын тоту;
- Иске Имән авылында вакытлыча көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын чистарту;
-Сарысаз Тәкермән т.п. көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын чистарту.
3) автомобиль юлларына, җирле әһәмияттәге күперләргә карата юл эшчәнлеге, шул исәптән торак пунктлар чикләрендә дә:
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында юлларны кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы
рәисе Р.Ә.Исламова